КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 16 май г.Казань № 326

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 22 гыйнвар, 22 нче; 2005 ел, 30 май, 239 нчы; 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы; 2007 ел, 6 апрель, 123 нче; 2008 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2010 ел, 29 ноябрь, 956 нчы; 2011 ел, 21 июнь, 496 нчы; 2011 ел, 6 декабрь, 1001 нче; 2012 ел, 13 апрель, 304 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 8 февраль, 80 нче; 2014 ел, 5 декабрь, 947 нче; 2015 ел, 15 апрель, 254 нче; 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче; 2016 ел, 22 июнь, 425 нче; 2017 ел, 10 май, 268 нче; 2017 ел, 28 август, 604 нче; 2017 ел, 27 октябрь, 812 нче; 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 7 март, 163 нче; 2019 ел, 5 август, 644 нче; 2019 ел, 10 декабрь, 1131 нче; 2020 ел, 2 июнь, 461 нче; 2020 ел, 11 сентябрь, 827 нче; 2020 ел, 5 ноябрь, 999 нчы; 2020 ел, 16 декабрь, 1141 нче; 2021 ел, 12 июль, 567 нче; 2021 ел, 13 август, 713 нче; 2021 ел, 28 сентябрь, 918 нче; 2022 ел, 11 март, 214 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1479 нчы; 2023 ел, 3 март, 200 нче, 2023 ел, 16 октябрь, 1313 нче, 2024 ел, 01 февраль, 53 нче, 2024 ел, 01 март, 108 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктның дүртенче абзацында «һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентларына» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.1 - 4.3 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. 6 яшькә кадәрге бала өчен дарулар сатып алуга субсидия (алга таба - дару чараларын сатып алуга субсидия) өч һәм аннан да күбрәк баласы булган, тәрбиягә

алган балаларны да кертеп, өлкән бала 18 яшькә яки белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге уку шартларында 23 яшькә җиткәнче фактта бала (балалар) аның белән яшәгән ата-ананың берсенә яисә аны алмаштыручы затка билгеләнә.

4.2. Бу Нигезләмәнең 4.1 пунктында күрсәтелгән гражданнар яки алар тарафыннан ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән затлар дару чаралары сатып алуга субсидия билгеләү өчен яшәү урыны буенча Үзәк бүлегенә түбәндәгеләрне тапшыра:

дару чаралары сатып алуга субсидия билгеләү турында гариза;

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсе күчермәләрен (булганда);

18 яшьтән 23 яшькә кадәрге баланың һөнәри белем бирү оешмасында, югары белем бирү оешмасында яисә укытуны гамәлгә ашыручы оешмада көндезге формада укуы факты турында белешмә;

әгәр дару чаралары сатып алуга субсидия билгеләү өчен гариза ышанычлы зат тарафыннан тапшырылса, ышанычнамә күчермәсен.

Документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган очракта, алар төп нөсхәләре күрсәтелеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныклана.

4.3. Үзәкнең бүлекчәсе ведомствоара соратулар нигезендә, шул исәптән электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасын кулланып, мәгълүматлар ала:

яшәү урыны буенча гариза бирүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында;

баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру турында;

балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында;

хезмәткәрнең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр түләү буенча бурычлары булуы (булмавы) турында;

18 яшьтән 23 яшькә кадәрге баланың гомуми белем бирү оешмасында уку узуы турында.»;

4.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.7. Дару чаралары сатып алуга субсидия билгеләгәндә гаилә составында түбәндәгеләр исәпкә алынмый:

тулысынча дәүләт тәэминатында торучы балалар (укуга бәйле рәвештә тулысынча дәүләт тәэминатында булган балалардан тыш);

ата-анасы (бердәнбер ата-анасы) ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән йә ата-ана хокуклары суд карары буенча чикләнгән балалар;

опекага бирелгән балалар;

никахлашуга яисә эмансипациягә бәйле рәвештә хокукый сәләтне алган балалар;

белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге бүлектә белем алмаган 18 яшьтән өлкәнрәк балалар.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.72 пункт өстәргә:

«4.7$^{2}$. гаиләсе составында 18 яшьтән өлкәнрәк балалары булган әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында күрсәтелгән гражданнарга (гомуми белем бирү

оешмаларында белем алучы балалардан тыш) дару чараларын сатып алуга субсидия түләү агымдагы елның 1 июленнән 1 ноябрьдән дә соңга калмыйча шушы Нигезләмәнең 4.2 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән документны тапшыруга кадәр туктатып торыла.

Әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән документ тапшырылганнан соң, дару чараларын сатып алуга субсидия бирү аны туктатып тору аеннан яңартыла.»;

4.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.8. Дару чараларын сатып алуга субсидия бирүне туктату өчен түбәндәгеләр нигез була:

гражданның бу Тәртипнең 4.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

дару чараларын сатып алуга субсидия билгеләнгән баланың вафат булуы;

ата-аналарның дару чараларын сатып алуга субсидия билгеләнгән балага карата ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителүе яисә ата-ана хокукларында чикләнүе;

дару чаралары сатып алуга субсидия билгеләнгән баланы опекага тапшыру;

тәрбиягә бала алган гаилә турындагы шартнамәнең гамәлдә булу срогы тәмамлану;

дару чараларын сатып алуга субсидия билгеләнгән баланың яшәү урыны алмашу;

һөнәри белем бирү оешмасыннан, югары белем бирү мәгариф оешмасыннан яки укытуны гамәлгә ашыручы оешмадан әлеге Нигезләмәнең 4.72 пунктының икенче абзацында билгеләнгән вакытта, 18 яшьтән 23 яшькә кадәрге баланы көндезге формада укытуны дәвам итүне раслый торган белешмә тапшырмау.

дарулар сатып алуга субсидия бирүне туктатып тору турында хәбәр ителгән көннән алып 90 көн эчендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләүләр буенча бурычларның җайга салынмавы.

Дару чараларын сатып алуга субсидия бирүне туктатып тору (торгызу), туктату турындагы карар дару чараларын сатып алуга субсидия бирүне туктатып торуга (торгызуга), туктатуга китерерлек хәлләр барлыкка килү турында документлар (белешмәләр) алган көннән алып 10 эш көне эчендә кабул ителә һәм субсидия алучыга дару чараларын сатып алуга субсидия билгеләү турындагы гаризада мөрәҗәгать итүче күрсәткән ысул белән (язмача почта адресы буенча, электрон документ рәвешендә электрон почта адресына, СМС-хәбәр рәвешендә телефонга) карар кабул итү датасыннан алып биш эш көне эчендә җиткерелә.»;

5 бүлек исемендә «гомуми белем бирү оешмалары укучыларына һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентларына» сүзләрен «гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга» сүзләренә алмаштырырга;

5.1 һәм 5.2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга юлда йөрү өчен айлык субсидия (алга таба - юлда йөрү өчен айлык субсидия) өч һәм аннан да күбрәк баласы булган, тәрбиягә алган балаларны да кертеп, өлкән бала 18 яшькә яки белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге уку шартларында 23 яшькә җиткәнче фактта бала (балалар) аның белән яшәгән ата-ананың берсенә яисә аны алмаштыручы затка билгеләнә.

5.2. Бу Нигезләмәнең 5.1 пунктында күрсәтелгән гражданнар яки алар тарафыннан ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән затлар транспортта йөрү өчен ай саен бирелә торган субсидия билгеләү өчен яшәү урыны буенча Үзәк бүлегенә түбәндәгеләрне тапшыра:

транспортта йөрү өчен ай саен бирелә торган субсидия билгеләү турында гариза;

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсе күчермәләрен (булганда);

чыгарылыш датасын күрсәтеп, чит ил дәүләте территориясендә бирелгән Россия Федерациясеннән читтә уку турында документның һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсе күчермәсен (ел саен уку елы башында тапшырыла);

18 яшьтән 23 яшькә кадәрге баланың һөнәри белем бирү оешмасында, югары белем бирү оешмасында яисә укытуны гамәлгә ашыручы оешмада көндезге формада укуы факты турында белешмә;

транспортта йөрү өчен ай саен бирелә торган субсидия билгеләү өчен гариза ышанычлы зат тарафыннан тапшырылса, ышанычнамә күчермәсен.

Документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган очракта, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныклана.»;

5.3 пунктның дүртенче абзацында «, чыгару датасын күрсәтеп, һөнәри белем бирү оешмасы» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.5 пунктта «юлда йөрүгә субсидия» сүзләрен «юлда йөрүгә айлык субсидия» сүзләренә алмаштырырга;

5.6 пунктта «Юл йөрүгә субсидия уку тәмамланганчы, әмма унсигез яшькә җиткәнче түләнә.» җөмләсен төшереп калдырырга;

5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Юлда йөрүгә айлык субсидия билгеләгәндә гаилә составында түбәндәгеләр исәпкә алынмый:

тулысынча дәүләт тәэминатында торучы балалар (укуга бәйле рәвештә тулысынча дәүләт тәэминатында булган балалардан тыш);

ата-анасы (бердәнбер ата-анасы) ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән йә ата-ана хокуклары суд карары буенча чикләнгән балалар;

опекага бирелгән балалар;

никахлашуга яисә эмансипациягә бәйле рәвештә хокукый сәләтне алган балалар;

белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге бүлектә белем алмаган 18 яшьтән өлкәнрәк балалар.»;

5.71 пунктта «юлда йөрүгә субсидия» сүзләрен «юлда йөрүгә айлык субсидия» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 5.72 пункт өстәргә:

«5.7$^{2}$. гаиләсе составында 18 яшьтән өлкәнрәк балалары булган әлеге Нигезләмәнең 5.1 пунктында күрсәтелгән гражданнарга (гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы балалардан тыш) юлда йөрүгә айлык субсидия түләү

агымдагы елның 1 июленнән 1 ноябрьдән дә соңга калмыйча шушы Нигезләмәнең 5.2 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән документны тапшыруга кадәр туктатып торыла.

Әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән документ тапшырылганнан соң, юлда йөрүгә айлык субсидия бирү аны туктатып тору аеннан яңартыла.»;

5.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Юл йөрүгә айлык субсидия бирүне туктату өчен түбәндәгеләр нигез була:

гражданның бу Тәртипнең 5.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

юл йөрүгә айлык субсидия билгеләнгән баланың вафат булуы;

ата-аналарның юлда йөрүгә айлык субсидия билгеләнгән балага карата ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителүе яисә ата-ана хокукларының чикләнүе;

юлда йөрүгә айлык субсидия билгеләнгән баланың опекага тапшырылуы;

тәрбиягә бала алган гаилә турындагы шартнамәнең гамәлдә булу срогы тәмамлану;

юлда йөрүгә айлык субсидия билгеләнгән баланың гомуми белем бирү оешмасында укуын тәмамлавы;

юлда йөрүгә айлык субсидия билгеләнгән баланың яшәү урыны алмашу;

юлда йөрүгә айлык субсидия бирүне туктатып тору турында хәбәр ителгән көннән алып 90 көн эчендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләүләр буенча бурычларның җайга салынмавы;

һөнәри белем бирү оешмасыннан яисә югары белем бирү мәгариф оешмасыннан әлеге Нигезләмәнең 5.72 пунктының икенче абзацында билгеләнгән вакытта, 18 яшьтән 23 яшькә кадәрге баланы көндезге формада укытуны дәвам итүне раслый торган белешмә тапшырмау.

Юл йөрүгә айлык субсидия бирүне туктатып тору (торгызу), туктату турындагы карар юл йөрүгә айлык субсидия бирүне туктатып торуга (торгызуга), туктатуга китерә торган хәлләр барлыкка килү турында мәгълүмат алынган көннән алып 10 эш көне эчендә кабул ителә һәм субсидия алучыга юл йөрүгә айлык субсидия билгеләү турындагы гаризада мөрәҗәгать итүче күрсәткән ысул белән (язма рәвештә почта адресы буенча, электрон документ рәвешендә электрон почта адресы буенча, СМС-хәбәр итеп телефонга) карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә җиткерелә.»;

әлеге Нигезләмәнең кушымтасында:

1 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Хезмәт яисә башка вазыйфаларны башкарган өчен, кызыксындыру характерындагы түләүләрне дә кертеп, бүләкләү, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт өчен, граждан-хокукый шартнамә кысаларында гамәлләр кылган өчен, шул исәптән түләүле шартларда опека яисә попечительлекне гамәлгә ашыру турындагы шартнамә буенча бүләкләү (тәрбиягә алган гаилә турында шартнамә, патронат гаилә турында шартнамә буенча), урнашкан (идарә) урыны булып Россия Федерациясе торган, бу затларга йөкләнгән идарә вазыйфалары фактта башкарылган яки

күрсәтелгән бүләкләү түләнгән урынга бәйсез рәвештә, Россия Федерациясе салым резиденты оешмасының (иректорлар советының яисә мондый башка органның) директорларын бүләкләү һәм идарә органы әгъзалары ала торган башка шундый ук түләүләр, Россия Федерациясе законнары нигезендә эш бирүче аша салым түләүгә хокук алуга бәйле рәвештә физик затлар керемнәренә кире кайтарылган салым суммаларыннан, шулай ук салым базасын яңартканнан соң салым чоры тәмамланганнан соң кире кайтарылган акчалар бирүдән тыш;»;

икенче, бишенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллану кысаларында алынган керемнәр.»;

2 пунктта:

җиденче абзацка «һәм халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт хезмәте органнары тарафыннан түләнә торган башка түләүләр» сүзләрен өстәргә;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мәҗбүри пенсия иминләштерүе турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда вафат булган иминләштерелгән затларның хокукыннан варисларына түләүләр;»;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«фәнни, фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча көндезге формада белем алучы һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында белем алучы затларга, рухани мәгариф оешмаларында белем алучы затларга түләнә торган Россия Федерациясе законнарында каралган стипендияләр һәм башка акчалата түләүләр, шулай ук күрсәтелгән категория гражданнарга медицина күрсәткечләре буенча академия ялында булу чорында компенсация түләүләре турында;»;

унынчы, унберенче, ундүртенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 ел, 24 март, 126 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 3 июнь, 370 нче; 2009 ел, 6 апрель, 203 нче; 2012 ел, 23 февраль, 153 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 25 август, 611 нче; 2015 ел, 23 сентябрь, 701 нче; 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче; 2016 ел, 22 июнь, 425 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 998 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 11 март, 168 нче; 2019 ел, 13 март, 181 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1173 нче; 2020 ел, 2 июнь, 461 нче; 2020 ел, 5 ноябрь, 999 нчы; 2020 ел, 16 декабрь, 1141 нче; 2021 ел, 20 февраль, 92 нче; 2021 ел, 10 май, 322 нче; 2021 ел, 12 июль, 567 нче; 2021 ел, 28 сентябрь, 918 нче; 2022 ел, 3 март, 194 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1479 нчы; 2023 ел, 11 июль, 809 нчы, 2023 ел, 16 октябрь, 1313 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы

Законының 2 статьясындагы 1 пунктының унынчы абзацында күрсәтелгән гражданнарга субсидия-ташлама өч һәм аннан да күбрәк бала булган очракта, тәрбиягә алган балаларны да кертеп, 18 яшькә кадәрге һәм (яисә) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада аларны көндезге уку рәвеше буенча укыту шарты белән 23 яшькә кадәрге яшьтә бирелә.»;

2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гаилә составында өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар, тәрбиягә алган балаларны да кертеп, өстәмә рәвештә һөнәри белем бирү оешмасында, югары белем бирү мәгариф оешмасында яисә укытуны гамәлгә ашыручы оешмада укытуның көндезге формасында 18 яшьтән 23 яшькә кадәрге баланы укыту факты турында белешмә тапшыра.»;

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Субсидия-ташлама күләме үзгәрүгә китерә торган хәлләр үзгәргән очракта (ташламалы затның гаилә составы үзгәрү, субсидия-ташлама алу өчен нигезләр үзгәрү), яисә субсидия-ташлама алу хокукын югалтуга китерә торган хәлләр барлыкка килгән очракта, субсидия-ташламаны исәпләү яңа нигез буенча башкарыла яисә хәлләр барлыкка килгән айдан соң килә торган айдан туктатыла.

Инвалидлык билгеләү срогы узганнан соң субсидия-ташлама түләүне туктатып тору башкарыла.

Субсидия-ташлама бирү ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә алынган мәгълүматлар нигезендә гражданны инвалид дип кабат тану аеннан яңадан башлана.

Гариза бирүченең кимендә иң күбе соңгы өч ел эчендә торак урыннар һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча барлыкка килгән, түләнмәгән һәм законлы көчкә кергән суд акты белән расланган бурычы булганда, субсидия-ташлама бирү әлеге бурычны түләп бетерү турында белешмәләр кергәнгә кадәр туктатып торыла.

Әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән гражданнарның салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына иминият кертемнәре түләүләр буенча бурычлары булганда, субсидия-ташлама бирү мондый бурыч турында мәгълүмат кергән көннән алып 90 көнгә туктатыла.

Субсидияләр-ташламалар бирү әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән гражданнар тарафыннан җайга салынганнан соң, салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына иминият кертемнәре түләүләр буенча субсидияләр-ташлама бирүне туктатып тору турында хәбәр ителгән көннән 90 көн эчендә яңадан торгызыла.

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 пунктының унынчы абзацында күрсәтелгән, гаилә составында 18 яшьтән өлкәнрәк балалары булган (гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалардан тыш), субсидия-ташламалар түләү агымдагы елның 1 июленнән агымдагы елның 1 ноябреннән соңга калмыйча әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктының уналтынчы абзацында күрсәтелгән документ бирелгәнче туктатыла.

Субсидия-ташлама бирүне торгызу турында карар кабул иткәндә, ул шулай ук ташламалар бирү туктатылган айлар өчен дә түләнә.

Субсидия-ташлама бирүне туктату өчен түбәндәгеләр нигез була:

ташламалы алучының яшәү урынын алмаштыру;

субсидия-ташлама алуга хокукны югалту;

әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән гражданнар тарафыннан салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына иминият кертемнәре түләүләргә субсидия-ташлама бирүне туктатып тору турында хәбәр ителгән көннән алып 90 көн эчендә җайга салынмау;

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 пунктының унынчы абзацында күрсәтелгән гражданнар, әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктының уналтынчы абзацында күрсәтелгән документны шушы елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча тапшырмау.

Субсидия-ташламалар бирүне туктатып тору (яңадан торгызу), туктату турындагы карар субсидия-ташламалар бирүне туктатып торуга (яңадан торгызуга), туктатуга китерерлек хәлләр барлыкка килү турында документлар (белешмәләр) алган яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән мәгълүматны үз эченә алган документларны тапшырган көннән алып биш эш көне эчендә кабул ителә. Субсидия-ташлама бирүне туктатып тору (яңадан билгеләү), туктату турында кабул ителгән карар хакында хәбәр итү субсидия-ташлама бирүне туктатып тору (яңадан билгеләү), туктату турында карар кабул ителгән көнне гариза бирүче тарафыннан субсидия-ташлама билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга СМС-хәбәр рәвешендә) гамәлгә ашырыла.»;

әлеге Нигезләмәнең кушымтасында:

1 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Хезмәт яисә башка вазыйфаларны башкарган өчен, кызыксындыру характерындагы түләүләрне дә кертеп, бүләкләү, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт өчен, граждан-хокукый шартнамә кысаларында гамәлләр кылган өчен, шул исәптән түләүле шартларда опека яисә попечительлекне гамәлгә ашыру турындагы шартнамә буенча бүләкләү (тәрбиягә алган гаилә турында шартнамә, патронат гаилә турында шартнамә буенча), урнашкан (идарә) урыны булып Россия Федерациясе торган, бу затларга йөкләнгән идарә вазыйфалары фактта башкарылган яки күрсәтелгән бүләкләү түләнгән урынга бәйсез рәвештә, Россия Федерациясе салым резиденты оешмасының (директорлар советының яисә мондый башка органның) директорларын бүләкләү һәм идарә органы әгъзалары ала торган башка шундый ук түләүләр, Россия Федерациясе законнары нигезендә эш бирүче аша салым түләүгә хокук алуга бәйле рәвештә физик затлар керемнәренә кире кайтарылган салым суммаларыннан, шулай ук салым базасын яңартканнан соң салым чоры тәмамланганнан соң кире кайтарылган акчалар бирүдән тыш;»;

икенче, бишенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллану кысаларында алынган керемнәр.»;

2 пунктта:

җиденче абзацка «һәм халыкны эш белән тәэмин итү  дәүләт хезмәте органнары тарафыннан түләнә торган башка түләүләр» сүзләрен өстәргә;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мәҗбүри пенсия иминләштерүе турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда вафат булган иминләштерелгән затларның хокукыннан варисларына түләүләр;»;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында белем алучы затларга, фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча көндезге формада белем алучы затларга, рухи белем бирү оешмаларында белем алучы затларга түләнә торган Россия Федерациясе законнарында каралган стипендияләр һәм башка акчалата түләүләр, шулай ук күрсәтелгән категориядәге гражданнарга медицина күрсәткечләре буенча академик ялда булу чорында компенсация түләүләре;»;

унынчы, унберенче, ундүртенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин